**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ НОВОАЛИМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423762, село Новое Алимово, улица Г.Тукая, дом 55.

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯҢА ӘЛЕМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

423762, Яңа Әлем авылы . Г.Тукай урамы, 55 йорт.

# РЕШЕНИЕ

«24» март 2025 ел. № 3

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 35 статьясы нигезендә, Совет Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге

карар итте:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматын рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) 2025 елның 31 мартыннан да соңга калмыйча бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга, торак пунктлар территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем җирлегенең түбәндәге адреслары буенча халыкка җиткерергә:

Яңа Әлем ав., Г. Тукай ур., 53 йорт (мәдәният йорты бинасы );

Иске Әлем ав., Центральная ур., 27А йорт (административ бина).

3. Карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Яңа Әлем авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе М.М.Исламов